БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_22_» __11___ 2019 г. № _359_

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә 2020 нче елга норматив чыгымнарны раслау турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 нче номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2020 елга расларга:

1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы балаларга сәнгать-эстетика юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелгән норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә 0,5 күләмендә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 нче пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникатив челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://baltasi.tatarstan.ru

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

1 нче номерлы кушымта
Татарстан Республикасы Балтач
район башкарма комитетының
2019 ел «_22_» __11__ _2019_
номерлы
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (бер укучыга 1 елга сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Бию сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Бию сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |